ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕНАЛИМСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЗАИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЮГАРЫ НАЛИМ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**09.12.2021** Югары Налим ав. **№ 26**

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Налим авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеген раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының $160^2$ статьясы 4 пунктының дүртенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Югары Налим авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Налим авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының төп администраторлары исемлеген кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Налим авыл җирлеге 2022 елга һәм 2023 - 2024 еллар (2022 елга) план чорына бюджетын төзегәндә һәм үтәгәндә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

Башкарма комитет
җитәкчесе Л.И. Сибгатуллин

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Зәй шәһәре
башкарма комитетының
09.12.2021 ел
26 номерлы карары
белән расланган.

## Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Налим авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеге

| Бюджет классификациясе коды | | Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Югары Налим авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторы исеме/ Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Налим авыл җирлеге бюджеты керемнәре төре (төрчәсе) кодының исеме |
|---|---|---|
| керемнәрнең баш администраторы | Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Налим авыл җирлеге бюджеты керемнәре төре (төрчәсе) | |
| 1 | 2 | 3 |
| 833 | Зәй муниципаль районы финанс-бюджет палатасы | |
| 833 | 0 10 50201 10 0000 510 | Зәй муниципаль районы Югары Налим авыл җирлеге бюджеты акча средстволарының башка калдыкларын арттыру |
| 833 | 0 10 50201 10 0000 610 | Зәй муниципаль районы Югары Налим авыл җирлеге бюджеты акча средстволарының башка калдыкларын киметү |

«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Налим авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеген раслау турында» Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Налим авыл җирлеге Башкарма комитеты карар проектына аңлатма язуы

«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Налим авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеген раслау турында» Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Налим авыл җирлеге Башкарма комитеты карар проекты (алга таба – карар проекты) «Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 1 июлендәге 251-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясы 17 пунктын гамәлгә ашыру максатларында әзерләнде, аның нигезендә Россия Федерациясе Бюджет кодексының 160.2 статьясы 4 пунктның 4 абзацы белән тулыландырылды, ул җирле администрация тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән гомуми таләпләр нигезендә җирле бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеген раслауны күздә тота.

Карар проекты җирле бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторын җирле администрация органнарына беркетүгә һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 16 сентябрендәге 1569 номерлы карары белән расланган җирле бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының төп администраторлары исемлеген раслауга карата гомуми таләпләрне исәпкә алып эшләнгән.

Югарыда күрсәтелгән федераль законның 4 статьясы нигезендә Россия Федерациясе Бюджет кодексының 160.2 статьясындагы 4 пункты нигезләмәләре Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының 2022 елга һәм 2023 - 2024 еллар (2022 елга) план чорына бюджетын төзегәндә һәм үтәгәндә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла.

Карарны гамәлгә ашыру Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Югары Налим авыл җирлеге бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.